СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №86 (7259) | 18 июль, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91" пресс-группасы хәбәр итә

Уңыш өчен көрәш районда көннән-көн киң колач ала бара. 17 июльгә кырларда 8442 гектарда игеннәр тезэмнәргә салынды. Бу барлык мәйданның 16 проценты кадәр дигән сүз. Хуҗалыклар төп игътибарны борчакны җыеп алуга юнәлтәләр. Бу культураның 51 проценты, ягъни 3568 гектары тезэмнәргә салынды. Әлегә суктыру аз—бары 90 гектарда гына.

Авыл эшчәннәре җир әзерләү, салам җыю кебек эшләрне дә икенче планга куймыйча, урак белән параллель алып барырга тырышалар.

# СЫНАТЫРГА ЯРАМАС

—Әнә безнең егетләр. Молодцы, күрәсезме, ничек чиста алып баралар борчакны.

Колхоз партоешма секретаре Н. Камалов сүзе белән килешми мөмкин түгел: комбайннар үткән җир ялап алгандай чиста кала. Юкса, мәйданны да ул кадәр тигез димәс идек!

—Бер яклап кына урабыз. Ике яклап төшеп караган идек тә—сыйфатка суга.

Рәшит Галиуллин комбайныннан төшә-төшүгә сүзгә катышты шулай. Рәшит абый—колхоз комбайнчыларының иң даимиләреннән. Менә ничә еллар инде ул кышын МТЗ-80 дә эшли, аннан комбайнын ремонтлап, ашлык җыярга чыга. Әлегә кадәр сенажга борчак урганнар, инде менә суктыру өчен дигәнен тезэмнәргә салалар. Ике комбайн алын алып, килешеп эшлиләр. Хәер, ике комбайн дигәннән, бу —гомумән бертуган Галиуллиннар алыны. Комбайнның икенчесе аның абыйсы —өлкән механизатор, алтын куллы оста Рафик Галиуллинныкы, ә ярдәмчесе—Казан Дәүләт педагогия институты студенты аның улы Алмаз. Әле Рафикны уртанчы улы Рәфис алыштыра. Хуҗалыкта моңа сүз әйткән кеше юк, чөнки беләләр: Галиуллиннар алындымы—эш булачак. Чөнки алар, кем әйтмешли, күперчеккә басар яшькә җитүгә, комбайн штурвалы артына утыралар. Рәфис тә ничә ел ярдәмче иде, мөстәкыйль комбайн алып эшләгән чаклары да булды. Инде хәзер ул Салдакай авылында укыта, ә җәйге каникулында олыгаеп барган этисенә ярдәм итәргә булды. Абыйсы Рунар, шулай ук укытучы, «Родина» колхозында мөстәкыйль комбайн алып уракта катнаша. Шулай итеп, Галиуллиннар үз икмәкләрен эшләп ашарга күнгәннәр. Менә хәзер дә кырга иртүк чыгалар, чык төшмичә басуны ташламыйлар. Рәшит абыйның ярдәмчесе Марат Хәкимов та җегәрле булырга ошый, сөбханалла. Алар әлегә, борчакны алганда уруда эшлиләр. Соңрак ашлыкны уруга күбрәк «Кормилец», чапкычларын тартачаклар. Егетләр исә суктыруга күчәчәкләр.

Уңыш турында сөйләшәбез. Әйе, быел әлләни сөендерергә охшамый ашлык. Бу кыр әле бераз уңыш бирер, ә менә беренче бригада басуы комлы булды, анда бөтенләй начар. Әмма ни булса да җыярга, бөртеген дә кырда калдырырга ярамый.

Басуда арырак эшләүче Рәшит Төхфәтуллин белән Җәмил Бәһаветдинов та шул фикергә кушылалар. Болар да инде 10 елдан артык басу иңләгән игенчеләр. Үзләре сөйләшәләр, күзләре—кырның теге очында баядан бирле тик торган комбайнда.

Якынрак киләбез. Фәнис Фәрдиев комбайны икән. Нәрсә булган аңа? Юкса Фәнис юктан гына борын төшерә торган түгел. Механизаторлык аның өчен шулай ук династия һөнәре. Әтисе Мөнир, агасы Рәшит Фәрдиевлар—шулай ук күптәнге механизаторлар. Фәнис үзе мәктәптә авыл хуҗалыгы техникасы нигезләрен укыта, ә җәен комбайнга утыра. Ватылуы җитди түгел, йөртү каешы гына өзелгән. Кәефсезлегенең сәбәбе башкада икән.

—Шул ремень аркасында мастерскойга кайттык. Килүенә менә сөт машинасы очрады тагы...

Менә сиңа мә! Ә техник ярдәм күрсәтү машинасы кайда? Ык-мык килгәч ачыкланды: техник ярдәм күрсәтәсе машина авыл халкыннан җыелган сөтне ташый, халыкка икмәк алып кайта икән. Сүз дә юк, болары да кирәк нәрсә. Инде уттай урак өстендә, ватыла-җимерелә калса, һәр комбайнчы шулай мастерскойга йөгерергә тиеш микәнни? Әгәр өстәвенә эретеп-ябыштыру агрегаты кирәксә?

Булмас димә—анысына да юлыктык! Уҗым арышы тезэмнәрен суктыручы В. Матвеев комбайны түбәсендә утырган ярдәмче Иван Матвеев олы юлдан күзен дә алмый.

—Эшләп булмады бүген рәтләп. Бер бункер тутырып озаттым гына—бушату муфтасы сынып чыкты. Мастерскойга кайтып, ябыштырып килдем.

Менә шулай! Ул дәвам итә:

—Инде килгән җиремә машина югалды. 2 сәгатьләп көтәм—һаман юк.

Шоферы Рәшит Миндубаев икән. Шундый уттай кызуда 2 сәгать эш туктатып тору эчне пошырмаслык түгел, әлбәттә.

Сүз дә юк, эш барышында андый хәлләр генә булыр да, үтәр дә. Тик техник ярдәм күрсәтү машинасының булмавын ничек тә аклап булмый. Чөнки «Алга»да комбайннар 100 проценты белән югары сыйфатлы әзерләнгән дип әйтеп булмый. Комбайннар кадрлар белән соң комплектланды, әле берсенә соңгы көннәрдә генә НУРБдан комбайнчы таптылар, ул сафка да басмаган. Ә ашыгып көйләгән техника икеләтә игътибар сорый, икеләтә куркыныч тудыра. Моны хуҗалыкның инженерлык службасы ничек күздән ычкындырган—аңлашылмый. Ә басуларда эш кайный. 1 бригада кырыннан ындыр табагына ашлык кайта (сүз уңаеннан, быел ындыр табаклары асфальтланган, кадрлар тупланган). Бүген-иртәгә борчакны да суктыруга керешәчәкләр. Башлангыч бар, игенчеләрдә эшләү теләге көчле—аны сүндермичә механизаторларга тиешле шартлар тәэмин итәсе, уракны үз вакытында, сыйфатлы үткәрәсе иде! Сынатырга ярамый!

С. ХӘЙРУЛЛИНА,
«Алга» колхозы.



## Һәркемгә үрнәк

Илдар Гайнуллин, дистәдән артык уракны күргән тәҗрибәле комбайнчы, быелгы бәйгегә дә зур күтәренкелек, әзерлек белән чыкты. Тырышлык, осталык һәм тәҗрибә аңа һәр елдагыча «Татарстан» колхозы комбайнчылары арасында алдынгы урыннарның берсен сакларга мөмкинлек бирер дип уйлыйбыз. Ә әлегә хуҗалык уракка әйбәт кенә керешеп китте. Иң зур куркыныч тудырган борчак тезэмнәргә салынды, инде аны суктыру бара. Илдар Ильясович та шул эш белән мәшгуль. Һәрвакыттагыча, тиз һәм сыйфатлы эшләве белән колхоз комбайнчыларына үрнәк ул.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы комбайнчысы И.И. Гайнуллин.

В. Никонорова фотосы.

## Рәис сайланды

«Чишмә» колхозы колхозчыларының гомуми җыелышында колхоз рәисе Х. Х. Шәйхетдинов сәламәтлеге какшау сәбәпле шәхси гаризасы нигезендә эштән азат ителде. Колхоз рәисе итеп бертавыштан моңарчы «Рассвет» совхозында управляющий-агроном булып эшләүче Рөстәм Искәндәрович Хәнәфиев сайланды.

## Игътибар:
## „Иң яхшы сөрүче" конкурсы

23 июльдә «Россия» колхозында «Иң яхшы сөрүче» исеменә район конкурсы үткәрелә. Туңга сөрүдә катнашасы механизаторларны конкурста катнашырга чакырабыз. Ул ике этапта үткәреләчәк. 1 этапта конкурста катнашучылар теоретик сорауларга җавап бирәләр. II этапта практик сәләтләрен күрсәтәләр. Конкурста җиңүчеләрне Мактау грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр көтә.

Игенчеләрне хезмәт бәйгесенә көтәбез. Конкурс шартлары турында җентекле мәгълүматлар хуҗалыклар җитәкчелегенә җиткерелә. Анда катнашырга теләүчеләр гаризаларын оештыру комитетына бирергә тиешләр.

Телефон: 2-24-45, район авыл хуҗалыгы идарәсе.

ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ.

## Бердәмлектә көч

Бу аренда звеносы дүрт кешедән тора: Рафик Төхвәтов, Шамил Гатин, Әдип Солтанов һәм Әхәт Галимов. Соңгысы аренда звеносына җитәкчелек итә. Әхәт яшь, энергияле кеше булып чыкты. Алар яңа гына чөгендер басуыннан төшке ялга кайтканнар иде. Рәт араларына тамырдан тукландыру үткәрәләр. Тукталышлары—Иске Әмзә авылы башындагы искерәк кенә бер мастерской икән.

—Безгә монда җайлы,—дип аңлатты арендачылар.—Колхозның машина-трактор паркына кайтып җиткәнче, шактый вакыт уза. Ә биредә без тиз генә ватылган техниканы төзәтә алабыз, кирәкле детальләрне алыштырабыз.

Арендачыларның һәр хәрәкәте эштән курыкмауларын әйтеп тора. Барысы да яшьләр.

—Узган елны көз аенда төнге сәгать бердә, җирләр туңдыргач чөгендер алырга чыктык,—ди көлеп звено җитәкчесе.—Белсәгез иде, мускуллар үтереп сызлый, ләкин эшләргә. Һәркемнең теләгендә татлы тамырны булдыра алган кадәрле булса да алып калу иде шул.

Хәзер звено карамагында 80 гектар уҗым культуралары, 30 гектар арпа, 25 гектар солы, 80 гектар чөгендер бар. Әнә шулардан яхшы уңыш алырга өметләнәләр. Аларның бөртекле һәм бөртекле-кузаклыларны суктыру өчен «Нива», КС6-Б чөгендер алу комбайннары, көпчәкле һәм чылбырлы тракторлары эшкә һәрчак әзер тора.

Дөрес, проблемалар да байтак. Һәр механизаторга кирәк булган комбайн каешлары һәм башка төр детальләрне таба алмыйча интегәләр.

Шулай да арендачылар сыкранмый. Яхшы киләчәккә ышаналар. Ә хәзер таркалмыйча, бердәм эшләргә исәпләре.

Г. РӘХИМОВА,
«Комбайн» колхозы.



## Шәхси хуҗалыклар өлеше

Киекле авыл Советы алдан төзелгән килешү нигезендә шәхси хуҗалыклардан 2 мең 40 центнер сөт җыеп тапшырырга тиеш.

Киекле участогы буенча Суфия Билалова аеруча тырышлык куеп эшли. Ул көненә 650 килограммга кадәр сөт җыя. Роза Хуҗиәхмәтова, Сәрия Мөхәммәтова, Кизләүдән Фәһимә Фәхретдинова һәм башкалар да үз эшләренә җаваплылык хисе белән карыйлар.

Сөтне тапшыруда Үрнәктән Мәйсәрә Садыйкова (640 килограмм), Гәдәния Нигъмәтуллина (718 килограмм), Әсләм Мингалимов (715 килограмм), Кизләүдән Галимҗан Гыймалетдинов (650 килограмм) аеруча активлык күрсәтәләр. Мондыйларга кызыктыру чарасы йөзеннән колхоз 0,30 гектар печән җире бүлеп бирә.

Р. ГАЛИЕВА,
авыл Советы секретаре.

# Алга таба ничек яшәргә?

**Х. Х. МОРАДЫЙМОВ,**
халык депутатларының район Советы председателе,
КПСС райкомының беренче секретаре.

Илдәге тирән экономик, политик һәм рухи кризис, дәүләт һәм хезмәт дисциплинасының кискен йомшаруы, милләтара мөнәсәбәтләрнең кискенәюе, кеше үлеменә китерә торган җинаятьчелек, көчләүнең үсүе, коррупция, спекуляция, эчкечелек һәм наркомания, әхлаклылыкның кимүе һәм бу җәһәттән ил һәм республика хөкүмәтләренең хәлиткеч чаралар кабул итмәве район коммунистларында тирән борчу тудыра.

Коммунистларның һәр нәрсәне үз исеме белән атар, үзгәртеп кору турында лыгырдаган булып, властьсызлыкны законлаштыру, тере яңару эшен лозунг-митинг стихиясенә батырырга, ә эштә исә җинаятьчел максатларда властьны үз кулына алырга теләүчеләргә кискен каршылык күрсәтер көннәре җитте. Бүгенге ситуацияне бәяләп, иң элек соңгы елларда планлы рәвештә, уйлап, төгәл сценарий буенча алып барылган яшертен сугышның яңа стадиясе башлануын билгеләргә кирәк. Бу сугыш партиягә каршы алып барыла, имеш. Әммә дөресрәге, ул җәмгыятебезнең төп тормыш структурасына каршы бара һәм җәмгыять, озак һәм акрын гына булса да, моны аңлый башлады.

Бүген безнең максат—үзгәртеп коруга мөмкин кадәр күбрәк нәтиҗәлелек белән барлык кешеләрне, һәр башлангыч партоешманы тарту, районда башланган үзгәрешләрнең алга таба да дәвам итәсенә ышанычлы гарантия булдыру. Бу җәһәттән эш берничә юнәлештә алып барылырга тиеш.

Бүген базар шартларында партиянең эшчәнлеге нинди буласын ачык күзаллау, һәр партия оешмасының, һәр коммунистның, беренче чиратта коммунист-җитәкчеләрнең районндагы һәм хезмәт коллективларындагы социаль-экономик һәм иҗтимагый-политик тормышын стабильләштерү юнәлешендә конкрет чараларын билгеләү зарур.

Авыл эшчәннәре алдында да проблемалар байтак. Бу иң элек промышленность һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре арасындагы эквивалентсыз алмаш һәм ул бәяләрнең тигезсез күтәрелүендә ачык чагыла.

Колхоз һәм совхозлар хәзергәчә җитештергән продукцияләренең хуҗасы була алмыйлар. Алар җитештергән продукция азык-төлек налогы һәм дәүләт заказы рәвешендә хуҗалыклардан алына. Шул ук вакытта азык-төлек налогы бәяләре дәүләт заказы белән чагыштырганда 8—10 процентка түбәнрәк. Мондый шартларда мөстәкыйльлек турында сүз алып бару, әлбәттә, урынсыз.

Терлекчелектәге хәлләр дә шуннан алып түгел. Дүрт айлык нәтиҗәләрдән күренгәнчә, без узган ел белән планлаштырган алга китеш сизелми.

Ит җитештерүдә рентабельлелек аеруча түбән.

Әммә шул ук вакытта районда киләчәктә продукция җитештерү һәм әзерләүне арттыру өчен база барлыгын әйтергә кирәк. Безгә калса, башлангыч партия оешмалары, безнең оппонентлар тәнкыйтенә бирелеп, производство мәсьәләләрен хәл итүдән бик тиз котылдылар.

Шулай да яңалык үзенә юл яра. Азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итүдә яңа экономик мөнәсәбәтләргә күчү бермә-бер булышачак. Башлангыч оешмаларга биредә бер позицияне алу зарур.

«Крестьянга ирек бирегез, һәм ул халыкны туендырыр» дигән лозунгны һәр бәладән, һич югы якын бишьеллыкка, панацея итеп санап булмый.

Чаралар комплексы кирәк. Билгеле, крестьянның җир хуҗасы булуы кирәк, аның җирдә ныклап һәм җитештерүчән хезмәтенә комачауламаулары зарур.

Кешеләргә кайда яшисен, ничек яшисен, нәрсә эшлисен үзләренә сайлау мөмкинлеге тудырырга кирәк. Безнең бурыч—аларны бер-берсенә каршы куярга түгел, ныклы хуҗалык элемтәләренә булышырга, милек һәм хуҗалык итү формаларының позицияләрендә тигез хокуклылык тәэмин итәргә, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүдә бөтенесенә бертөрле шартлар тудырырга.

Без политик эшчәнлегебезнең үзегенә крестьян мәнфәгатьләрен куярга, аны җиренең хуҗасы итеп раслау өчен тырышырга тиешбез.

Азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләләрендә промышленность предприятиеләре дә күпне башкара алалар. Биредә партия оешмалары һәм администрациягә шефлык ярдәменнән ничегрәк котылу чарасын эзләргә түгел, ә киресенчә —бу мәсьәләне практик ясылыкка куеп, кешеләрне бу эшнең мөһимлегенә инандырырга, системалы эшне җайга салырга кирәк. Яздан ук үзара файдалы килешү төзү зарур. Ярдәм җибәрүләрен көтәргә түгел, мөмкинлек булган кадәр үз көчебез белән шикәр чөгендере сирәкләү, аннан аны җыюны оештырырга кирәк.

Тулаем алганда, анализ күрсәткәнчә, районның базарга керү юнәлешендә старт шартлары идеаль түгел. Бүген бөтенебез бер нәрсәне аңларга тиешбез: партия оешмалары һәм коммунист-җитәкчеләр эшчәнлегендә хәлиткеч, координаль чаралардан башка экономик сферада без проблемалардан арына алмаячакбыз гына түгел, бөтенләй яши дә алмаячакбыз. Бу чараларның әйбәтләп уйланылган һәм халык тарафыннан хупланган булуы мөһим.

Партия оешмаларының эшендә базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында икенче юнәлеш булып дәүләт бәйлелегеннән азат итү һәм приватизация аша кешенең милеккә хокукын тормышка ашыруны турыдан-туры аңлату һәм аңа катнашу тора.

Экономиканың социаль юнәлеше беренче чиратта милекне нәкъ менә халыкка кайтарудан гыйбарәт. Приватизация һичшиксез ирекле булырга тиеш һәм коллективлаштыруның кирәсен хәтерләтергә тиеш түгел.

Районда беренче чиратта дәүләтчел булмаган структураларны приватизацияләү чаралары күздә тотыла. Боларга сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү, ремонт-төзелеш оешмалары керә.

Киресенчә, дәүләт бәйлелегеннән азат итү кемнәрнеңдер хокукларын кысу һәм төрле законсызлыклар белән алып барылырга мөмкин. Шуның өчен партия оешмалары дәүләт һәм башка җәмәгать оешмалары белән берлектә бу процесска ныклы контроль булдырырга, киң хәбәрдарлык һәм кешеләр белән киңәшләшү шартлары тудырырга тиешләр. Базар мөнәсәбәтләре социаль яклау проблемасының кискенлеген алга куя. Ә ул күпчелек халыкның заманча аңлавында түбәндәге мәгънәгә кайтып кала:

җәмгыятьнең һәр члены билгеле бер дәрәҗәдәге тормыш шартлары белән тәэмин итәрдәй, хезмәт өлешенә һәм башка факторларга бәйсез рәвештә дәүләттән ярдәм алуны гарантияләүче ниндидер бер система төзелергә тиеш дип күзаллана.

Мондый гадиләштерү кирәкмәс иде, чөнки без бу иждивенчылык кәефләрен тагын да көчәйтергә, экономиканың дистабилизацияләнүенә күбрәк ярдәм итәргә мөмкин.

Экономикада базар мөнәсәбәтләре шартларында социаль политиканың яңа алымнарын эшләгәндә без түбәндәге принциптан тайпылмаска тиешбез: социаль иждивенчылыктан — социаль гарантиягә. Иң гомуми формада алганда дәүләтнең социаль гарантияләре кешенең ирекле хезмәткә булган хокукын яклаудан, җәмгыятьтә гражданнарның шәхси куркынычсызлыгын тәэмин итүдән, тормыш стандартларына җавап бирердәй яшәеш системасын булдырудан гыйбарәт. КПСС райкомының чираттагы пленумы социаль яклау программасы нигезе итеп нәкъ менә шушы принципларны алды.

Бүгенге көндә шунысы ачык, социаль гарантияләр базар экономикасы үсешенә каршы түгел, ә нәкъ менә шул үсеш аркасында тәэмин ителәчәкләр.

Әлбәттә, базар үзенең законнарын көчләп тага һәм шуңа күрә тормышның барлык очракларына да бөтен нечкәлекләрне алдан күреп бетереп булмый, әмма без аз керем алучыларның тормыш дәрәҗәсен тиешенчә тәэмин итү өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә тиешбез. Безгә хәзер үсешнең капиталистик юлын көчләп такмакчы булалар, шул ук вакытта нык үскән илләр аралана алмаган бәла һәм чуаннар турында дәшмәү дә дәвам итә. Теләсәк-теләмәсәк тә бу хәл ветераннарга күләгә сала, аларның тормыш юлы тоташ хаталар чылбыры рәвешендә бәяләнә. Бу күрсәтмәләр яшьләргә соңгы инстанциядә хаклык итеп җиткерелә, әмма алар болай да җитди кимү кичергән әхлаклылыкны ныгытырга булышмыйлар.

Бу процесска битараф кала алмыйбыз, чөнки кеше акылы һәм йөрәге өчен килешмәүчән көрәш бара бит.

Моннан чыгу юлы бармы? Безнең тарихыбыз, партиянең роле, Ленин турында дөреслекне аңлату кирәк. Бүген без сафларыбызны нығытып, булган нәрсәләрне сукырларча якларга гына тиеш түгелбез, ә эшчәнлегебезне дөреслекне эзләүгә һәм аны гади кешеләргә җиткерүгә юнәлтергә тиешбез.

Бүген КПСС үз үсешенең сыйфаты ягыннан яңа этабына керде: дәүләт власте һәм партия функцияләрен чикләү үткәрелде. Хокукый дәүләттә булырга тиешле нәрсә бу.

Ә күпчелек кешеләрнең аңында партия элеккечә үк экономика, барлык социаль тормыш белән идарә итүче буларак яши. «Партия һәммәсен дә хәл итә», «Барысы да партиядән тора» дип сакланган стереотип бүген бик куркыныч.

Бу безнең политик оппонентларыбыз өчен отышлы. Алар конструктив эш оештыра һәм нәтиҗәгә ирешә алмауларын тагы партия хисабына акламакчы булалар. Шуңа да алар «Никадәр начаррак, шулкадәр яхшырак» лозунгысын кулланып аны беренче чиратта партияне дискредитацияләүгә юнәлтәләр.

Моннан партиянең принципиаль яңа, әле туып кына килә торган функциясе килеп чыга—политик оппонентлык һәм конструктив оппозиция.

Бу функция җирле, югары башкарма һәм закон чыгару властьлары органнарының эше хезмәт кешеләрен берләштерүче катлам һәм төркемнәрнең интересларына кагылган очракта һәм барыннан да элек шул очракта гына яшәргә мөмкин. Ягъни хезмәткә һәм торакка, сәламәтлек саклауга һәм культура байлыкларыннан файдалануга, белемгә булган хокукка куркыныч янаганда.

Югарыда аталганнар барысы да һәрбер партоешмада зур аңлату эше үткәрүне сорый. Һәрбер башлангыч оешмада мөстәкыйльлекне тормышка ашыру механизмы эшләнергә тиеш. Бу механизмнан белеп, җитди файдаланырга кирәк. Ә моның өчен кешеләр белән киң күләмдә эшләү, системалы уку кирәк.

Бүгенге көндә безнең күп кенә партоешма секретарьларына Устав буенча бирелгән мөстәкыйльлек кирәкми—чөнки «югарыдан» килгән әмер буенча яшәве җиңелрәк. Күпләре интеллектуаль һәм оештыру ягыннан аптыраш хәлендә. Без һәммәбез дә билгеле бер дәрәҗәдә үзгәреш көтү һәм сүз гипнозы астында яшибез. Шул ук вакытта без һәммәбез башлангыч партия оешмасында элементар практик эшләрнең параличлануын күреп торабыз һәм еш кына сүзсез шаһитлар булып кала бирәбез.

Бүгенге көндә барыбызга да бер нәрсә ачык мәгълүм булырга тиеш: без халыкның югалган ышанычын кайтару өчен авыр көрәшкә чыктык. Бу авыр көрәштә һәр башлангычка, һәр партия комитетына нигезле, үтемле һәм һәркемне үзенә тарта торган хәрәкәт программасы әзерләргә һәм иң мөһиме, аны үтәүне белеп оештырырга кирәк.

В. И. Ленин әйткәнчә, практик эш һәрчак иң яхшы программадан мөһимрәк.

Әгәр һәр партия оешмасының бүгенге иң мөһим бурычы турында кыскача гына әйтеп китсәк, ул Устав буенча яшәүгә тизрәк өйрәнү, яңа обстановкага җайлашу, үзләренең кече уставларын оешма тормышында раслау кебек эшләрдән тора.

Төп мәсьәлә: башлангыч оешма хезмәт коллективына кирәкме яки юкмы икәнлегенә тиз җавап бирү зарури. Моңа җавап бер генә булырга мөмкин: әгәр ул хезмәт ияләренең политик һәм социаль интересларын чагылдыруны оештыручы көч кебек хәрәкәт итсә—кирәк, әгәр үзенең эчке интереслары белән генә мәшгуль фикердәшләр сыман гына хәрәкәт итсә—кирәге юк.

Бүгенге кебек катлаулы социаль-экономик һәм политик обстановкада район партия оешмаларының кайберләре «үз йөзләрен» табалмады әле һәм абруй югалу да, КПСС сафларыннан күпләп китү дә шуннан башлана.

Узган ел тулаем район партия оешмасыннан 103 кеше китте. Шунысы ачык, бер яктан рәтләрне чистарту процессы бара. Ә урынга яраклашучыларны, карьерачыларны кызганырга түгел. Партиядән китүчеләр арасында андыйлар бар иде. Шуңа да күз йомарга ярамый, партия сафларыннан актив коммунистлар, бигрәк тә эшче һәм крестьяннар күп китте. Биредә сәбәпләр катлаулы. Һәм аларны ачыклап партия эше һәм башлангыч партия оешмалары эшчәнлеген яңарту буенча комиссиягә, партком һәм башлангыч партия бюроларына җентекләп тикшерергә кирәк. КПСС сафларыннан чыгулар быел да дәвам итә. Беренче ярты елда 54 кеше партбилетын тапшырды. НУРБ, депо, район больницасы, машина төзү заводы, геофизика, «Норлатнефть» НГДУсы, Мичурин исемендәге, «Восход» колхозлары партия оешмаларында партиядән чыгу өчен 10—12 шәр кеше гариза бирде.

КПССның эшлеклелеге, кешеләрнең тормыш хәле бүген партия членнарының эшчәнлегенә, эчке дисциплинаның ныклыгына турыдан-туры бәйле. Билгеле, килеп туган бурычларны тикшергәндә фикер ирегә бирелергә, бер-береңнең аргументларына игътибарлы караш булырга һәм бөтен көч кабул ителгән карарларны үтәүгә тупланырга тиеш. Партиянең сугышчан хәрәкәт итүче оешма буларак төп яшәеше әнә шунда да.

КПССның яңаруына, политик һәм партия структурасы формалашуга бәйле процесслар кайбер коммунистларның карашында, тулаем партоешманың эшчәнлегендә аерым чуалчыклар китереп чыгаруын дәвам итә.

Ләкир партоешмаларның идеологик, политик-тәрбия эшендә яңа үсентеләр артуын әйтеп китми мөмкин түгел. Алар индивидуальлектә, авырлыкны конкрет категориядәге шәхескә аударуда чагыла. Җәмәгатьчелек аңының ныклыгы, шәхеснең политик позициясе халыкны шашынган антикоммунизм һәм милләтчелектән саклауны тәэмин итә. Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге, «Татарстан» колхозлары, 1 нче, 2 нче урта мәктәпләр, Норлат разведка бораулавы идарәсе һәм башка партия оешмаларында мондый мисаллар аз түгел.

Боларның барысына да карамастан, партия эшенә анализ кайбер башлангыч партия оешмаларында күпчелек коммунистларның политик активлык дәрәҗәсе төшүен дәлилли.

Бүген партия оешмаларына идеология эшенең эффектлылыгын заман таләпләре югарылыгына күтәрү өчен төп нигез булган берничә шартны үтәргә кирәк.

Барыннан да элек, башлангыч партоешмалар, партиянең сугышчанлыгын күтәрүнең төп шарты буларак, коммунистларның идея чыныкканлыгын күтәрүгә чын-чынлап ирешергә тиешләр. Һәр коммунист, масса өчен көрәшнең ленинчыл формасы безнең өчен актуаль булды һәм ул шулай

# Алга таба ничек яшәргә?

булып кала да.

Идеология эшенең активлыгын ныгытуда политик көрәшнең тагын да үтемләрәк формаларын һәм алымнарын өйрәнү һәм үстерү зарури. Барыннан да элек, нәкъ биредә—партия алмашында, коммунистлар арасында караш һәм интереслар плюрализмы ирек һәм хәрәкәт бердәмлегенә әверелергә тиеш тә.

Партиянең көче аның массалар белән бәйләнешендә, массаларның аны аңлавында һәм яклавында икәнлеген тормыш безгә үзе раслый. Әмма бу эшләр кешеләрнең тормышы, аларның ихтыяҗлары турында көндәлек кайгырту партия эшенең үзәгендә, аның югары максаты булганда гына тормышчанга әверелә.

Безнең барлык идеологик эштә коммунистларда һәм партиясезләрдә патриотик һәм интернациональ сыйфатлар тәрбияләүгә приоритет юнәлеш итү бик мөһим.

Партоешмаларның идеологик комиссияләренә идеология кадрлары һәм активының хезмәт ияләре арасындагы, коллективтагы урыны һәм роле турында уйланырга кирәк. Чөнки аларның күбесенә тирән теоретик белем, идеологик практика җитенкерәми. Аларны бу сәнгатькә штаттагы идеология хезмәткәрләре өйрәтергә тиеш.

Массакүләм информация чаралары практик эшчәнлеккә иң зур әһәмият бирүне таләп итә.

Партиядән чыгучы һәр кеше белән индивидуаль һәм җентекле эш алып бару—безнең турыдан-туры бурычыбыз.

Илдә бара торган үзгәрешләр коммунистларда газаплы уйланулар тудыра һәм алар аның белән урталашырлар иде. Бу очракта җыелышларда, аерым аңгәмәләрдә кешеләрне тыңлый белергә кирәк. Коммунистлар бер-берсенең ярдәмен тоярга тиешләр. Шул чакта алар теләсә нинди мәсьәләне җиңел хәл итә алачаклар.

Уңнан да һәм сулдан да һөҗүм барган шартларда партиянең югары катлау җитәкчеләре генә түгел, бәлки төп звено—предприятие, совхоз һәм колхозларның башлангыч партоешмалары да тәнкыйть утына эләгә. Бу хәлдә партия хезмәткәрләрен, бигрәк тә башлангыч партоешма секретарьларын социаль яклау турындагы мәсьәлә бөтен нечкәлеге белән килеп баса.

Безнең бурыч—башлангыч партоешма секретарьлары өчен уңайлы эш шартлары тудыру һәм аларның хезмәт хокукларын яклау, аның эшчәнлегендәге мораль һәм материаль стимуллар турында кайгыртучанлык күрү.

Һәм тагын, партиянең оештыру функциясендәге төп нәрсә—дисциплина турында. Дисциплинасыз без партия түгел, ә мавыгулар буенча клуб, секта, кешеләр төркеме генә. Безне моңа күп нәрсә этәрә.

Ә бит дисциплинаны ныгытмый һәм тәртип булдырмый торып, һәркайда демократизация процессын тирәнәйтү һәм үстерү мөмкин түгел. Бүген кешеләр тарафыннан социаль гаделлек, партия членының сафлык һәм намуслылыгы мәсьәләсе бик кискен кабул ителә.

Һәм иң мөһиме—каушап калу һәм гамьсезлек полосасыннан ашыгыч чыгу.

Партия сафларын КПССның социалистик курсы үзгәрешсез калуга, социализмны, Советлар властен яклау, Совет Социалистик Республикалар Союзын саклау турында тирәнтен инану барлык коммунистларның уртак эше дип таныганда гына ныгытып була.

Партиягә кабул итүне оештыру буенча эшнең политик әһәмиятен күтәрергә, аны гомумпартия эше итеп санарга, хезмәт коллективларында яңа көчләр эзләргә кирәк. Алар партиябез кушканча, үзгәртеп коруны тормышка ашыру белән кызыксынучылар булсын.

Хәзер КПСС сафларына коммунистик идеяләргә бирелгән егетләр һәм кызларны кабул итүгә әһәмиятне арттырырга кирәк. Партия оешмалары партия сафларын үстерү өчен резерв итеп комсомолның ролен күтәрүгә чакырылганнар. Комсомолга якын килергә, бу максатта партия-комсомол җыелышлары, пленумнары һәм башка бергә-бергә чаралар үткәрүне практикага кертергә кирәк. Сугыш һәм хезмәт ветераннары, укытучылар, ата-аналар, башка абруйлы коммунистлар яшьләрне партиягә сайлау һәм хәзерләүдә күп эшләр башкара алалар.

Бу көннәрдә КПСС сафларына керүчеләрне кайгыртучанлык белән чолгап алу—икенче мәсьәлә. Аларны партия эшенә актив тарту, һәркайсының поручениесе, аерым эше булу турында кайгыртырга кирәк. Аларның көчен хезмәт коллективларында, халык арасында агитация алып баруда файдалану, җәмәгать оешмаларында һәм комсомолда партия линиясен үткәрү максатка ярашлы һәм файдалы булачак.

Барлык башлангыч партия оешмаларында да үз сафларының торышын кичектергесез тикшерергә, халык әйтмешли, үз өендә тәртип булдырырга кирәк. Партиядән аерылган һәркем белән индивидуаль эш үткәрү зарури.

Урыны партиядә булырга тиешсезләргә карата аяусызлык күрсәтергә, Совет законнарын бозучыларны, үзләренең кыйланышлары яки хәрәкәтләре белән КПССның авторитетын төшерүчеләрне партия сафыннан чыгарырга кирәк. Партиядә «членлыкны туктату» кебек спекуляцияне фаш итәргә, аның КПСС Уставына каршы килүен аңлатырга һәм бу эшнең партиядән чыгу турында гариза итеп каралуын белдерергә кирәк. Еш кына кешеләр КПСС сафларыннан ситуацияне начар аңлау нәтиҗәсендә чыгалар. Алар КПССка каршы бәндәләрнең пропагандасы йогынтысына бирелəләр яки моны шәхси муллык һәм үз тынычлыклары өчен эшлиләр. Партиядән чыгарга карар кылган кешеләрнең гаризаларын карауга, ачыктан-ачык иптәшләрчә сөйләшүгә киткән вакытны кызганмаска тиешбез. Мондый сөйләшүләрнең кешегә хаталарын танырга ярдәм иткән бик күп мисалларны беләбез.

Ләкин партия сафларыннан чыгучыларны политик һәм мораль яктан читләштерүгә юл куярга һич тә ярамый. Бигрәк тә элеккеге КПСС членына дошман итеп карауга чик куярга тиешбез. Үз кыйланышларының ашыгычлыгын аңлаучыларның партиягә кире кайту мөмкинлеген исәпкә алып, аларның партия стажы сакланырга тиеш. Ә мондый фактлар тормышта еш очрый. Билгеле, бу КПСС белән көрәштә үзен пычратмаучыларга гына хас нәрсәләр.

Әлеге авыр вакытта һәр иптәшне—коммунистны игътибарсыз калдырмау мөһим бурыч. Коммунистларны, бигрәк тә адресларына читләтеп һәм турыдан-туры янау, мораль террор, кысрыклау булганда сайланган активны социаль һәм хокукый яклауның эшлекле системасы булырга тиеш.

Партияле бердәмлек һәм иптәшлекне яңадан торгызырга кирәк. Хәзерге катлаулы заманда коммунистларның очрашуларын ешрак оештыру, коллектив тормышының иң мөһим проблемаларын, райондагы хәлне тикшерү буенча кыска вакытлы җыелышлар үткәрү максатчан булыр иде. Аларда үз позициянне, конкрет хәрәкәт планын эшләү зарури.

Андый җыелышларны беркетмәләү белән мавыкмаска, коммунистларга конкрет задание бирү һәм аның үтәлешен тикшерүгә игътибар юнәлтергә кирәк.

Алда безне катлаулы, билгесез юл көтә. Хәзер иң мөһиме—барлык көчне, энергияне һәм иҗади потенциалны беренче бурыч—кризисны тизрәк җиңү, халыклар арасында тынычлык, бердәмлек, барлык демократик үзгәртеп кору көчләрен туплау.

Партия оешмасының хәзерге шартларда ничек эшләве, сугышчанлыгы, массалар арасында идеология һәм оештыру эше үткәрүгә җәмгыятьне туплау, аның кризистан чыгу юлындагы уңышы, экономик хәлнең яңаруы кешеләрнең тормыш хәлен яхшыртуны тәэмин итүгә һәрьяклап булышачак.

Хәзер төрле партия, группировкалар арасында политик көрәш кискенләшә. Һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, «идея базарында» күпчелек халыкны үз ягына туплаган көч җиңәчәк. Коммунистларның яңарган партиясендә шушындый тарихи шанс бар һәм без алардан файдаланырга бурычлы.



**Комбайнчы. Нинди горур яңгырый бу исем! Син үзеңә бу һөнәрне сайлап алгансың икән, димәк, аны акларга да тиешсең.**

**«Знамя Октября» колхозында байтак еллар комбайнчы булып эшләүче Петр Антонович Журавлев бу исемгә тап төшерми, туган колхозы кырларында тырыш һәм намуслы хезмәт куя.**

**Петр Антонович агымдагы елда да урактан читтә калмады. Хәзер ул арышны теземнәргә салуда катнаша.**

**Рәсемдә: комбайнчы П. А. Журавлев.**

## Безнең коллективта

Дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә бүгенге көндә 7160 дуңгыз бар. Аларны бирегә район хуҗалыкларыннан дүрт айга кадәр (авырлыклары 35—40 килограмм) үстереп китерәләр. Продукциянең үзкыйммәте район хуҗалыкларында асралучыларга караганда күпкә ким, чыгым да аз тотыла. Биредә рационга зур әһәмият бирелә: һәр дуңгызга составына микро- һәм макроэлементлар, антибиотиклар кертелгән катнаш азык бирәләр. Цехларда исә азык РК-1000 торбасы аша таратыла.

Агымдагы елның алты аенда 7208 баш дуңгызны 7552 центнер авырлыкка гына җиткерә алдык. Моның сәбәбе шунда, район хуҗалыкларыннан берләшмәгә соңгы вакытларда дуңгызлар бик аз китерелә. Бу яктан бары «Рассвет» совхозы, «40 лет Победы», «Россия», Хафизов исемендәге колхозлар гына уңышлы эшлиләр.

Коллективта хезмәт сөючән уңганнар байтак. Шундыйлардан Анатолий Александрович Захаров бригадасын атап үтәргә була. Алар үз карамакларындагы дуңгызлардан 475 әр грамм уртача тәүлеклек артым алуга ирештеләр. Эшчеләр алты айлык дуңгызларны 105—110 килограммга җиткереп ит комбинатына тапшыралар.

Бездә эшләүчеләр өчен шартлар да тудырылган: алар график буенча отпуск алалар, сораучыларга ял йортларына һәм санаторийларга путевкалар бирелә. Буыннар сызлаганда, радикулиттан һәм башка чирләрдән интеккәндә Түбән Чаллы авылында урнашкан профилакторийга барып дәвалана алалар.

Безнең коллективта өч милләт халкы шулай тату яши һәм эшли.

**Ә. ГАФИЯТУЛЛИН,**
дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмә директоры.

## Яңа цех эшли

ЕЛЕЦ шәһәрендә күптән түгел махсус төзелгән медицина кораллары заводында бер тапкыр кулланыла торган үтә дә дефицит шприц эшләп чыгарыла башлады. Бу цех тугыз ай эчендә төзелеп сафка кертелгән һәм монда озакламый елына йөз миллион шприц эшләнәчәк.



**Андриян Федушкин «Правда» колхозының беренче товарлыклы-сөтчелек фермасында җиңел булмаган хезмәттә эшли: ул—көтүче. Җәйге эсседә дә, көзге салкын җилләрдә дә җаваплылык аның өстендә. Шуңа да ул намус белән, зур тырышлык куеп эшли. Хәзерге вакытта Андрияның инде тугыз еллык эш стажы бар. Аз түгел бу.**

**Рәсемдә сез көтүче А. Федушкинны күрәсез.**

## „Ислам һәм Литва татарлары“

**4 июльдә Вильнюста шундый исемдә күргәзмә ачылды. Бу күргәзмә литва татарлары бәйрәмен башлап җибәрде. Борынгы документларга караганда, биредә яшәүче татарлар алты елдан Балтыйк буена күчеп утыруның 600 еллыгын билгеләп үтәчәкләр. Алар күбесе җирле гадәтләрне, телне үзләштерсәләр дә, мөселманнар булып калганнар. Алар өчен беренче намаз йорты 1930 елда Каунаста ачыла, әмма сугыштан соң ул ябыла. Хәзер Каунас мәчете кабат ачылды. Аны ачу тантанасына СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Тәлгать Таҗетдин килде. Хәзер Литвада 6 меңгә якын татар яши.**

# Киләсе очрашуга кадәр

**Район терлекчелек тармагы өчен бу ел катлаулы килде. Сөт, ит җитештерү, аны дәүләткә сатуның торышы үткән елгыдан кайтыш булу ярты ел дәвамында күп тапкырлар җитди сөйләшүгә сәбәпче булды. Әмма район терлекчеләр көне барыбер кәефле, бәйрәм төсендә үтте. Мактанырлык урын булмаганда, аны тыйнаграк итсәң дә яраган булыр иде, диючеләр дә табылды. Без бу фикер белән килешә алмадык һәм менә ни өчен..**

Сүз дә юк, бөтен эшнең нәтиҗәсе аның ахыр күрсәткече белән бәяләнә. Әмма ахыр нәтиҗәләрнең нинди булуы ай-һай күп сәбәпләргә бәйле! Ул көнлек, атналык тырышлыктан гына түгел, ничә елларга сузылган эзлекле, даими хезмәттән тора. Монда нәсел эше дә, рационны дөрес төзү дә, башка зооветталәпләр дә, хезмәтне оештыруда уйлап эш итү дә—һәммәсе, һәммәсе дә кирә. Болар хакында слетта җентекләп тәҗрибә бүлешерлек алдынгылар байтак саналды. Иң элек бу турыда кышлату чоры нәтиҗәләре буенча призлы урыннарга чыккан «Рассвет» совхозы, «Россия» һәм «Комбайн» колхозлары терлекчеләре сөйли алырлар иде. Беренче яртыеллык нәтиҗәләре буенча алдынгылыкны яулаган «Большевик», «Үрнәк» колхозлары һәм «Мамык» совхозы товарлыклы-сөтчелек фермалары мөдирләре В. В. Кузнецов, И. М. Шәрәфетдинов, Г. М. Сардионов та байтак нәрсә өстәрләр иде. Районда инде иң тотрыклы, иң эшчән аренда коллективы буларак дан казанган З. Х. Гобәйдуллин («Рассвет» совхозы), В. В. Ермошкин («Заря» колхозы) һәм Т. Т. Кыямов («40 лет Победы») звенолары членнары өчен дә уңышка ирешү юллары сер түгел. Слетның бу яктан терлекчеләр өчен әһәмияте бәяләп бетергесез: фикер уртаклаш, сөйләш, таныш, сораш. Юкса, кеше кулыннан килмәстәй нәрсә түгел ләбаса уңыш дигәнең! Әнә Дан флагы бүген Роза Галимҗановна Хәммәдиева исемен хөрмәтләп җилферди, ул үз группасындагы маллардан 21 әр килограмм сөт сава. Әмма бу—аның очраклы, үз уңышы гына диеп карап булмый, үрнәкләре соңгы июнь аенда да сөт җитештерү һәм сату буенча районда җиңеп чыктылар, һәр сыердан бу чорда 506 килограмм сөт җитештерделәр. Уңыш шулай бердәм, даими хезмәт нәтиҗәсендә туа, ә уңганнарның да уңганнарына җиңүнең дә зурысын китерә. Шәхси беренчелек өчен ярышта һәр сыердан беренче яртыеллыкта 2410 килограмм сөт сауган Рәшидә Минвафовна Шәрипова («Рассвет» совхозы), Зинаида Ивановна Павлова («Сөлчә» совхозы), Минзифа Сабирҗановна Гәрәева, Нәҗия Хәлиулловна Бильданова («Таң» колхозы), беренче кат бозаулаган сыерлардан иң күп сөт алуга ирешкән Кәшифә Хөснулловна Шәкүрова («Таң»), Зәйнәп Шәрипова («Чирмешән»), Людмила Николаевна Михеева, (Мичурин исемендәге) бу көнне шундый хөрмәтләүгә лаек булдылар.

Хәер, алдынгылар күп аталды, хөрмәтләүләр зур булды бәйрәмдә. Бозау караучылар Надежда Алексеевна Семенова («1 нче Май»), Сәлимә Мирзаҗановна Мәҗитова («Игенче»), Нина Васильевна Прагашкина (Синдряков исемендәге), Нина Владимировна Осипова («Россия»), сөт ташу машинасы шоферы Солтан Минәхмәтович Хөснулов (40 лет Победы), алдынгы терлекчеләр Каюм Сәмигуллович Ибәтуллин («Үрнәк» колхозы), Хәниф Вәлиәхмәтович Шәрипов («Рассвет» совхозы), лаборантка Гөлсинә Сәмигулловна Хәлимова («40 лет Победы») һәм башкалар, һәм башкалар хөрмәтенә мактау да яуды, бүләкләр дә бирелде, җыр да яңгырады. Әлбәттә, алдынгылар исемнәре болар белән генә тәмамланмады, аларны санап чыгу мөмкин дә түгел. Иң мөһиме—алар үз хезмәтләренә кадер артуны тойдылар, хөрмәтне сизделәр. Хәзерге кытлык чорында да район потребительләр җәмгыяте, нефтьчеләр, тимер юлчылар, урман промышленносте хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре матур итеп табын корганнар, бүләкләр, азык-төлек наборлары әзерләгәннәр. (Әмма аларны таратуны әлегәчә тантана барышында оештыру гына күңелгә ятып бетмәде). Шунда ук халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе хезмәте оештырылды, Модалар ательесы сезон киемнәреннән модалар күрсәтү үткәрде, Мәскәүдәге «Уен» коллективы чыгышына үзебезнең үзешчән сәнгать көчләре җырлары кушылды, кибетләр, ашханә эшләде, аукцион гөрләде. Боларның һәммәсен терлекчеләр өчен бик урынлы, бик кирәкле зурлау дип таптык. Аны терлекчеләр көнендә аларны котлап сүз алган район Советы рәисе, КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов чыгышыннан да тоеп була иде.

—Кыен кышлату, авыр ел булды,—диде Хәлил Хәмзиевич агымдагы елга анализ биреп, әмма бу вакытлыча авырлык. Быелгы җәйдә маллардан мул продукция алуны тәэмин итәрлек фураж, азык запасы тупларга кирәк, ә инде сезнең хезмәткә килгәндә, без аңысына һәрчак исәп тота алабыз. Рәхмәт сезгә!

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ә. Н. Рәхмәтуллин яртыеллык күрсәткечләрне анализлап ясаган чыгышында район терлекчеләре алдында торган бурычларны билгеләде.

Бәйрәм кәеф күтәрерлек тантаналы, күңелле үтте. Киләсе шундый очрашу тагы хезмәт күрсәткечләре белән дә балкырлык булсын—һәркемнең уртак теләге шундый иде.

**С. НУРУЛЛИНА.**

# Телевидение

**ШИМБӘ**
**20 ИЮЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

18.15 Мультфильм.
18.35 «Бергәләп өйрәник» тапшыруына кушымта.
19.00 Татарстан.
19.30 Туган җир моңнары. (Башкорт телевидениесе).
19.50 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 Шаян сәхнә.
21.35 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Док. фильм. «Багышлану».
6.45 Мультфильмнар.
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге почта.
8.30 ТЯХ.
8.45 Безнең бакча.
9.15 Балаларыбыз өчен саклыйк.
9.25 Санау ноктасы.
9.55 Бельгия—Европа тыкрыгындагы ил.
10.55 Таң йолдызы.
11.55 «Бурда моден» тәкъдим итә..
12.25 Сурәт.
13.30 Әкиятләр һәм мажаралар дөньясында. Нәфис фильм. «Кызыл башмаклар».
15.15 Бер бәла астында берләшәчәк безнең Русь.
16.25 «Биюгә бирелгән тормыш». Фильм-концерт.
17.30 Мультфильм: «Бал корты Майя». 7 серия.
17.55 Халыкара панорама.
18.40 Режиссер Б. Шәмшиев фильмнары. «Бүре чокыры».
21.00 Вакыт.
21.40 Бәхетле очрак.
22.40 Еллар аша елмаю.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильм.
8.30 Тынлы оркестр уйный.
8.45 «Кеше. Җир. Галәм».
9.30 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
12.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
14.00 Рус теле.
14.30 Док. фильм.
15.30 «Педагогика һәркем өчен».
16.30 «Җырымны отып кал». Олылар һәм балалар өчен.
17.00 Владимир шәһәрендә «Чикләр» фестивале.
21.40 «Рогмузимпорт».
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «Сынаулар сәгате». Нәфис фильм.
00.15 Юртаклар дөньясында.

**ЯКШӘМБЕ**
**21 ИЮЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

18.05 «Сәфәр» үзәгенең «Рамазан» татар җыры бәйрәме.
19.35 Әлли-бәлли-бәү.
19.45 «Сәфәр» үзәгенең «Рамазан» татар җыры бәйрәменең дәвамы.

**I ПРОГРАММА**

8.30 Биржа яңалыклары.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 Иртән-иртүк.
10.00 Ватанга хезмәттә.
11.00 Иртәнге почта.
11.30 Сәяхәтчеләр клубы.
13.00 Сәламәтлек.
13.30 Мультфильмнар.
14.15 Сез моны булдыра аласыз.
15.15 Яңа буын сайлый.
16.30 Нинди күзлектән карыйсың бит.
17.05 Авыл сәгате.
18.05 Тавышлар күп — дөнья бер генә.
18.10 Уолт Дисней күрсәтә.
19.00 Делегатскаядагы музей.
19.15 Нәфис фильм: «Олылар һәм балалар».
21.00 Вакыт.
21.40 Кинопанорама.
21.55 Футбол күзәтү.
22.25 Хронограф.

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Зарядкага басыгыз».
8.20 Мультфильмнар.
8.50 Концерт.
9.30 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
12.00 Фил Донахьюның «Спид» программасы.
13.05 «Лосев» әңгәмәләре...» 3 нче тапшыру.
14.00 Концерт.
14.30 Режиссер М. Дохматская фильмнары.
16.15 Нәфис гимнастика. СССР чемпионаты.
17.00 Зур булмаган музыкаль кичәләр.
21.00 Вакыт.
21.40 «Коллаж».
22.15 «Профессионаллар. Һәвәскәрләр». Күңел ачу программасы.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «Әкиятләр аланы». Нәфис фильм.

# Балалар турында кайгыртып

«Заречный» пионерлагере әкияттәгедәй гүзәл Чирмешән елгасы буенда урнашкан. Балалар биредә яхшылап ял итсеннәр өчен бөтен шартлар да булдырылган. Беренче сменада эшләүчеләр моңа ышандылар. 16 июльгә укучылар кабаттан пионерлагерьга кабул ителәчәкләр һәм ата-аналарга балаларын көтелмәгән хәлләрдән саклап калу өчен мөмкинлек туа. Чөнки, аларның күзәтүсез калулары аркасында районда суга батып үлүчеләр саны артты бит.

Лагерьда балалар даими рәвештә тәҗрибәле тәрбиячеләр һәм пионервожатыйлар күзәтүендә булачаклар. Аларны мавыктыргыч ярышлар, хәрәкәтле уеннар һәм бик күп төрле кызыклы чаралар көтә.

Балаларны пионерлагерьга урнаштыру өчен шикәр заводының профсоюз комитетына яисә эш урынының профсоюз комитетына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Путевка бәясе ата-аналар өчен 20 сумнан да ким түгел.

**Е. ШАШОРИНА,**
агропромышленность комплексы работникларының профсоюзының район комитеты инструкторы.



**Железногорск шәһәрендә Дмитриевлар гаиләсе яши. Ата-ана, балалар. Леонид Валерьевич һәм Валентина Николаевнаның үзләренең 5 баласы бар һәм тагын 5 баланы тәрбиягә алдылар. Валентина Николаевна опекун гаиләнең тәрбиячесе—үзенең кыен эше өчен хезмәт хакын дәүләттән ала. Леонид Валерьевич—«Магнит» техник үзешчән иҗат үзәге директоры. Беренче каттагы 7 бүлмәле ике фатирда яшиләр. Өй җиһазларын Леонид Валерьевич үз куллары белән ясаган. Валентина Николаевна ятимнәрне тәрбиягә алырга Әрмәнстанда җир тетрәү булганнан соң карар кыла. Ире һәм әнисе белән киңәшә. Һәм шуннан соң гаиләдә иң элек Максим, аннары Лена, Оля, Лина, Света барлыкка килә.**

**...Хәзер Валентина Николаевна өлкәдәге беренче гаилә кибетенең мөдире булып эшли. Аңа балалары ярдәм итә. Нәниләр исәпләргә, төгәллеккә, тәртипкә өйрәнәләр.**

**Рәсемдә: Леонид Валерьевич балаларны булачак йорт белән таныштыра.**

**ТАСС фотохроникасы.**

**БЕЛДЕРҮ**

**Шәһәр мунчасы 1991 елның 18 июленнән эшли башлый.**

«Агропромхимия» берләшмәсе администрациясе, партия, профсоюз һәм ВЛКСМ комитетлары шофер
ФӘРИТ МИНВАЗЫЙХ улы
ИЛЬМУХИНның
фаҗигале рәвештә үлүен белдерәләр һәм аның туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклашалар.

**МӨХӘРРИР Ө. У. АБДУЛЛИН.**


**Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 86. Тираж 3415.**